# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 25 октябре № 3

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2023 елда 800 (Сигез йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Алан-Бәксәр авылында балалар мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын урнаштыру, мәйданчыкта куркынычсыз шартлар тудыру, материаллар, декоратив үсемлекләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Алан-Бәксәр авылында янгын куркынычсызлыгы өчен шартлар булдыру – янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;

- Алан-Бәксәр авылында кышкы айларда юлларны карап тору (урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Алан-Бәксәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тотуны (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру)

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2022 елның 25 октябрендә 15 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 217 (Ике йөз унҗиде) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 112 кеше, бу 51,6 % тәшкил итә;

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 112 (Йөз унике) кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 (ноль) катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 800 (Сигез йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Алан-Бәксәр авылында балалар мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын урнаштыру, мәйданчыкта куркынычсыз шартлар тудыру, материаллар, декоратив үсемлекләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Алан-Бәксәр авылында янгын куркынычсызлыгы өчен шартлар булдыру – янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;

- Алан-Бәксәр авылында кышкы айларда юлларны карап тору (урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Алан-Бәксәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, төзекләндерү һәм карап тотуны (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам утлары өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру)

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы: З.Р.Гарифуллина